КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1535

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте концепциясен раслау турында» 2023 ел, 9 февраль, 116 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте концепциясен раслау турында» 2023 ел, 9 февраль, 116 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Республика башкарма хакимият органнарына Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашырганда бу карарга теркәлгән Концепцияне кулланырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашучы оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә әлеге Концепцияне куллануны тәкъдим итәргә.»;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте концепциясенең 4 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәте субъектлары – республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашучы башка органнар, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин